ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «24» маеннан № 148

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта торакны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 12 сентябрендәге 249 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендәТатарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта торакны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 12 сентябрендәге 249 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта торакны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Админитратив регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Административ регламентның 1.5 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йорттагы торакны яңадан планлаштыру мондый торакның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән һәм (яисә) яңа тораклар барлыкка килүдән гыйбарәт, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган һәм

(яисә) аның эчке планлаштырылуын үзгәрткән очракларда, (шул исәптән торакның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртмичә). Яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә шулай ук чиктәш торакларның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәрергә мөмкин. Яңадан планлаштыру чикләр һәм (яисә) торак (тораклар) мәйданы турында яисә төзелгән торакларга дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру һәм төзелгән торакларга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов